ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16 ноябрь 2017 ел № 7007

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары, шәһәр Уставы, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турындагы нигезләмә, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлекләрен раслау турында» 2013 елның 9 апрелендәге 2393 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) кушымтада каралганча расларга.

2. Үз көчен югалтуны танырга:

1) Башкарма комитетның «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 10 июнендәге 3480 номерлы карары;

2) Башкарма комитетның 2013 елның 10 июнендәге 3480 номерлы карары белән расланган «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 31 гыйнварындагы 533 номерлы карары;

3) Башкарма комитетның «Челнинские известия» газетасының 2016 елның 22 июлендәге 53 нче санында бастырып чыгарылган «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 27 июнендәге 3277 номерлы карары;

4) Башкарма комитетның «Челнинские известия» газетасының 2017 елның 1 мартындагы 14 нче санында бастырып чыгарылган «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 22 февралендәге 934 номерлы карары;

5) Башкарма комитетның «Челнинские известия» газетасының 2017 елның 24 мартындагы 20 нче санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 17 мартындагы 1388 номерлы карарының 1 пункты.

3. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә. А. Галиәкбәровага әлеге карарны «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгаруны, шулай ук аны «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Р.Ә. Абдуллин

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2017 елның 16 ноябрендәге
7007 номерлы карарына
кушымта

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) товарлар җитештерүгә (сатуга) бәйле чыгымнарны (акциз товарларыннан, җиңел автомобильләр һәм мотоциклlardan, Россия Федерациясе территориясендә җитештерелгән виноградтан тыш) кайтару, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүгә (алга таба – муниципаль хезмәт) бәйле чыгымнарны кайтару максатларында юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: юридик затлар һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Башкарма комитет) исеменнән Башкарма комитетның финанс идарәсе (алга таба – финанс идарәсе) тарафыннан күрсәтелә.

1.4. Башкарма комитетның урнашу урыны: Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Башкарма комитетның эш графигы: дүшәмбе – җомга: 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр; шимбә, якшәмбе: ял көннәре. 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр төшке аш вакыты.

Финанс идарәсенең белешмә телефоны: 30-56-79. Башкарма комитет бинасына керү шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.5. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты адресы: http://nabchelny.ru, финанс идарәсенең электрон почта адресы: nche.fbp@tatar.ru.

1.6. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары аша, гариза бирүчеләр белән эшләү өчен;

2) «Интернет» челтәре аша Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http:// www.nabchelny.ru);

3) Башкарма комитетта (финанс идарәсендә):

- телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

- язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта аша.

1.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендә мәгълүмати стендларда дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча финанс идарәсе белгече тарафыннан урнаштырыла.

1.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Бюджет кодексы (алга таба – РФ Бюджет кодексы) (РФ законнар җыентыгы, 03.08.1998, № 31, 3823 ст.);

2) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 06.10.2003 №40, 3822 ст.);

3) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 ст.);

4) «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 08.12.2014 № 49 (VI өлеш), 6928 ст.) (алга таба – 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон)

5) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 12.09.2016, № 37, 5506 ст.) (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары);

6) «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы) (Татарстан Республикасы, 03.08.2004 №155-156);

7) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Вәкиллекле органы тарафыннан 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы) («Челнинские известия» 10.12.2005, № 235-237, 30.12.2005, № 249-250);

8) Шәһәр Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетын раслау турындагы карары (алга таба – бюджет турында карар);

9) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 11 мартындагы147-р боерыгы белән расланган Эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

10) Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан 2017 елның 10 августындагы 777-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының финанс идарәсе турында нигезләмә (алга таба – финанс идарәсе турында нигезләмә);

11) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2007 елның 16 июлендәге 754 номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).

1.9. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 пункт). Гариза Регламентка 1 нче кушымта нигезендә тутырыла.

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан кертелгән һәм документка кертелгән мәгълүматларның (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе) документлардагы мәгълүматларга тәңгәл килмәвенә китергән хата (тасвирлама, басма, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

## 2 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне билгели торган норматив акт яки таләп |
|---|---|---|
| Муниципаль хезмәтнең исеме | Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү | РФ Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пункт |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтә торган җирле үзидарәнең башкару-боеру органы исеме | «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе исеменнән Башкарма комитетның финанс идарәсе | Шәһәр Уставы, Башкарма комитетның 2017 елның 10 августындагы 777-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының финанс |

| | | |
|---|---|---|
| | | идарәсе турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | 1) субсидия бирү турында шартнамә (Регламентка 2 нче кушымта);<br>2) субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе | РФ Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пункт;<br>бюджет турында карар |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату вакыты | Гариза теркәлгән вакыттан башлап 20 эш көненнән дә артык түгел | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук гариза бирүче тарафыннан күрсәтелергә тиешле хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең, гариза бирүче тарафыннан алардан файдалану ысулларының, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибенең тулы исемлеге | 1) хезмәт күрсәтү турында гариза;<br>2) гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;<br>3) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);<br>4) юридик зат өчен гамәлгә кую документлары;<br>5) товарлар җитештерү (сату), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү белән бәйле рәвештә алынмаган керемнәр һәм (яки) чыгымнар фактын раслаучы документлар;<br>Гариза һәм документлар бер нөсхәдә тапшырыла.<br>Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче | РФ Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге 887-ФЗ номерлы Карары |

| | | |
|---|---|---|
| | Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлеп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьләрдә түбәндәге ысулларның берсе белән бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:<br>- шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч язуы нигезендә эш итүче зат);<br>- почта аша заказлы тапшыру турында белдерү кәгазе белән.<br>Гариза һәм документлар, шулай ук, гариза бирүче тарафыннан, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша имзаланган электрон документ рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны гариза бирүчеләр тарафыннан алу | Субсидия алучының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге 887-ФЗ номерлы карарының 4 пунктындагы «е» пунктчасында каралган таләпләргә туры килүен раслау өчен ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар, анда шартнамә төзү планлаштырыла торган айның беренче числосына:<br>1) ЕГРЮЛдан мәгълүматлар яисә ЕГРИПтан мәгълүматлар; | 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| ысуллары, шул исәптән электрон формада. | 2) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булган бурычның булмавы турында мәгълүматлар;<br>3) бухгалтерлык балансыннан мәгълүматлар (шул исәптән керемнәр һәм чыгымнар турында хисап);<br>4) Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына кире кайтару буенча кичектерелгән бурычның, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләренең, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына кире кайтару буенча кичектерелгән бурычның булмавы турында мәгълүматлар һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты алдында кичектерелгән башка бурычлар;<br>5) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карарының 3 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән максатларга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетыннан субсидияләр бирү планлаштырыла торган акчалар алу (алмау) турында мәгълүмат. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, | 1) Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы; | Эш регламенты |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | 2) яшәешнең тиешле өлкәсенә кураторлык итүче Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары яисә тармак органы башлыгы (алга таба – тармак органы җитәкчесе);<br>3) Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) документлар тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылу;<br>2) документларның тиешле органга бирелмәве | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр юк<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы;<br>2) дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына караган оешманың муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яисә) мәгълүмат булмауны таныклаучы ведомствоара запроска җавабы һәм (яисә) мәгълүматның булмавын таныклаучы, тиешле документ гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган булса, дәүләт хакимияте органының яисә җирле үзидарә органына яисә оешманың ведомствоара соратып алуына җаваплары | Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пункт |

| | | |
|---|---|---|
| | керү;<br>3) субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә түгел);<br>4) агымдагы календарь елына бюджет турында карарда каралган бюджет ассигнованиеләре булмау һәм (яисә) тиешле финанс елына бюджет билгеләнешләре суммасыннан тулысынча файдалану;<br>5) субсидия алучылар субсидияләр бирү турында шартнамә төзү планлаштырыла торган айның беренче числосына туры килергә тиеш булган таләпләргә туры килми. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм | Чират булганда, муниципаль хезмәттән файдалануга гариза бирү – 15 минуттан артык түгел. | |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел. | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү урынына инвалидлар өчен тоткарлыксыз керү тәэмин ителә (биналарга керү-чыгу һәм алар эчендә хәрәкәтләнү уңайлы булырга тиеш).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы гариза бирүчеләргә уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикле булуын исәпкә алып | 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.15. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:<br>1) Башкарма комитетның җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>2) кирәкле санда белгечләр, шулай ук документлар кабул ителә торган бүлмәләр булу;<br>3) мәгълүмат стендларында, | |

| | | |
|---|---|---|
| дәвамлылыгы, муниципаль хезмәттән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә файдалану мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникацион технологияләрдән файдаланып | «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең мәгълүмат ресурсларында (http://www.nabchelny.ru), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>4) инвалидларга башка затлар белән бертигез хезмәтләрдән файдалануга комачаулык итүче каршылыкларны үтәргә ярдәм күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>1) документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>3) муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;<br>4) муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затларның гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, КФҮнең читтәге эш урыннарында консультация, документларны кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара. | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәттән электрон рәвештә файдалану тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү аша яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин. Әгәр законда муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны электрон рәвештә бирү каралган булса, ул очракта, гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru) яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http:// www.gosuslugi.ru) аша бирелә. | |

3 бүлек. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүчегә бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү.

Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен финанс идарәсенә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша яисә электрон формада мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Финанс идарәсе белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы, эчтәлеге һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы, эчтәлеге муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча буенча консультацияләр.

3.3. Гариза бирүче шәхсән яисә вәкаләтле зат аша эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон формада электрон почта kancel.chelny@tatar.ru яки Интернет-кабул итү аша җибәрелә.

3.4. Гаризалар кабул итүче эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) гариза бирүченең шәхесен ачыклауны;

2) гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч язуы буенча эш иткән очракта);

3) әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерүне.

3.5. Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) гаризаны бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында кабул итү һәм теркәүне;

2) гариза һәм документларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне.

3.6. Регламентның 2.8 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, гариза бирүчегә гаризаны һәм документларны кире кайтара.

Регламентның 3.4. – 3.7. пунктларында билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) гариза һәм документлар кабул итү – 15 минут эчендә;

2) гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән гариза һәм документлар яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.7. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза һәм документларны карап тикшерә һәм гариза һәм документларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет

Җитәкчесе урынбасарына, финанс идарәсе башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.8. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы гариза һәм документларны карап тикшерә һәм карап тикшерү өчен аларны финанс идарәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: финанс идарәсе белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.9. Финанс идарәсе белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша Регламентның 2.6 пунктында каралган мәгълүматлар бирү турында запросларны җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән запрослар.

3.10. Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, сорала торган документларны (мәгълүматларны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында белдерү кәгазе җибәрәләр (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән очракта, документлар (мәгълүматлар) бирә торган органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: финанс идарәсе белгеченә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.11. Финанс идарәсе белгече алынган документларны (мәгълүматларны), шулай ук Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны туплый һәм карап тикшерү өчен аларны, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган юридик затларны (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләрне, шулай ук физик затларны – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләрне сайлап алу комиссиясенә (алга таба – комиссия) ведомствоара электрон хезмәттәшлек юлы белән җавап кергән көннән башлап бер эш көне эчендә җибәрә.

Комиссия утырышларының периодиклыгы Башкарма комитет карары нигезендә билгеләнә.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен комиссиягә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар).

3.12. Документлар (мәгълүматлар) алган көнне комиссия рәисе утырыш

датасын билгели. Комиссия утырышы комиссиягә документлар (мәгълүматлар) кергән көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча уздырылырга тиеш.

3.13. Комиссия үз утырышында юридик затларның (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), шәхси эшмәкәрләрнең, шулай ук физик затларның (алга таба – претендент) гаризаларын һәм документларын карап тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар комиссия утырышы көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында финанс идарәсенә җибәрелгән комиссия беркетмәсе.

3.14. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы беркетмәне һәм алынган документларны карап тикшерә һәм шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын әзерләү өчен финанс идарәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура комиссия секретареннан документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия беркетмәсе һәм финанслар идарәсе белгеченә җибәрелгән документлар.

3.15. Финанс идарәсе белгече комиссия беркетмәсе нигезендә:

1) субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын әзерләүне гамәлгә ашыра;

2) килештерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгыннан документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: субсидия бирү турында шартнамә проекты яки килештерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрелгән субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.16. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерә һәм килештерелгән документларны финанс идарәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына документлар кергән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы тарафыннан килештерелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки финанс идарәсе белгеченә җибәрелгән субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.17. Финанс идарәсе белгече субсидия бирү турында килештерелгән шартнамә проектын яки Башкарма комитетның тармак (функциональ) органы җитәкчесенә субсидияләр бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерүгә җибәрә.

Башкарма комитетның тармак (функциональ) органы җитәкчесе субсидияләр бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерә һәм аларны финанс идарәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура тармак (функциональ) органы җитәкчесенә документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тармак (функциональ) органы җитәкчесе тарафыннан килештерелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки финанс идарәсе белгеченә җибәрелгән субсидияләр бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.18. Финанс идарәсе белгече субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерү өчен Башкарма комитетның Хокук идарәсенә җибәрә.

Башкарма комитетның Хокук идарәсе тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында килешү проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерә.

Тапшырылган документлар норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, Башкарма комитетның Хокук идарәсе субсидия бирү турында шартнамә проектына яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектына кимчелекләр буенча күрсәтмәләр әзерли һәм әлеге кимчелекләрне төзәтү өчен аларны финанс идарәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура документлар Башкарма комитетның Хокук идарәсенә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: финанс идарәсе белгеченә җибәрелгән субсидия бирү турындагы шартнамәнең килештерелгән проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты яисә субсидия бирү турындагы шартнамә проектына яисә субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектына карата кимчелекләр.

3.19. Финанс идарәсе белгече:

1) Башкарма комитетның Хокук идарәсе тарафыннан килештерелгән субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә;

2) Башкарма комитет Хокук идарәсенең субсидия бирү турындагы шартнамә проектына яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектына карата кимчелекләрне төзәтә һәм проектларны килештерү өчен Башкарма комитетның Хокук идарәсенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Башкарма комитетның Хокук идарәсеннән документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе:

1) килештерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты;

2) төзәтелгән, килештерү өчен Башкарма комитетның Хокук идарәсенә җибәрелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.20. Башкарма комитетның Хокук идарәсе субсидия бирү турында

шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерә һәм аларны финанс идарәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура төзәтелгән документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитетның Хокук идарәсе тарафыннан килештерелгән субсидия бирү турында Башкарма комитетның карар проекты, субсидия бирү турында шартнамә проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.21. Финанс идарәсе белгече Башкарма комитетның Хокук идарәсе тарафыннан килештерелгән субсидия бирү турында шартнамә проектын яки имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитетның Хокук идарәсе тарафыннан килештерелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.22. Башкарма комитет Җитәкчесе субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын имзалый һәм аларны финанс идарәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган, финанс идарәсе белгеченә җибәрелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.23. Финанс идарәсе белгече гариза бирүчене субсидия бирү турында дүрт нөсхәдәге шартнамәне имзаларга чакыра. Гариза бирүче килгәч, имзалау өчен, аңа дүрт нөсхәдәге субсидия бирү турында шартнамәне бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче килгән көнне 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалау өчен гариза бирүчегә дүрт нөсхәдә бирелгән субсидия бирү турындагы шартнамә.

3.24. Гариза бирүче субсидия бирү турында шартнамә проекты белән таныша, дүрт нөсхәдәге субсидия бирү турында шартнамәне имзалый һәм теркәү өчен финанс идарәсе белгеченә кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура шартнамәне алганнан соң 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүче тарафыннан дүрт нөсхәдә субсидия бирү турында имзаланган шартнамә.

3.25. Финанс идарәсе белгече субсидия бирү турында шартнамәне терки, субсидия бирү турында шартнамәнең бер нөсхәсе гариза бирүчегә имза куйдырып бирелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура субсидияләр бирү турында шартнамәне имзалаганнан соң 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә субсидия бирү турында бирелгән шартнамә.

3.26. Финанс идарәсе белгече муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарткан очракта, субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын терки һәм гариза бирүчегә шәхсән бирә яки почта аша җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гамәлгә ашырыла:

гариза бирүче шәхсән килгән очракта – 15 минут эчендә;

җавапны почта аша хат итеп җибәргән очракта – Регламентның 3.22 пунктында каралганча, процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм гариза бирүчегә субсидия бирүдән баш тарту турында бирелгән (җибәрелгән) гариза.

3.27. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен КФҮләрдән документлар килгәндә процедуралар Регламентның 3.3. - 3.22. пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.28. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә бирә:

1) техник хатаны төзәтү турында гариза (5 нче кушымта);

2) гариза бирүчегә техник хата булган муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

3) техник хатасы булуны таныклаучы, юридик көчкә ия булган документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырыла.

3.29. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече техник хатаны төзәтү турында гариза кабул итә, теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны Башкарма комитет Җитәкчесенә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза.

3.30. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза һәм документларны карап тикшерә, гариза һәм документларны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.31. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы документларны карап тикшерә һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатыннан, Регламентның 3.6, 3.7, 3.15 - 3.22 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен алу белән шәхсән имза куйдырып яисә гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә биргәндә техник хата булган документның төп нөсхәсен бирү мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, Башкарма комитет вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

3) билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы булырга мөмкин (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләр кылуны тикшереп тору максатларында Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар тарафыннан билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контроль Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыра торган Башкарма комитетның вазыйфаи затлары исемлеге Башкарма комитет боерыгы белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең гаризаларын вакытында карап тикшерү өчен җаваплы.

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары әлеге Регламентның 5 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен Башкарма комитетның вазыйфаи затлары һәм башка муниципаль хезмәткәрләре законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

## 5 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм эш гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә Башкарма комитетка шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документларны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә Башкарма комитетка яки Башкарма комитет Җитәкчесенә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) рәсми сайтыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

5.6. Шикаять аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет Җитәкчесе (аны алмаштыручы зат) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актларында түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә, шулай ук башка формаларда;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм гариза бирүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән

җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, Башкарма комитет Җитәкчесе булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә

5.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затның карары, гамәлләре (гамәл кылмавы) Россия Федерациясенең гражданлык һәм арбитраж процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять ителергә мөмкин.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесенә
____________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында
гариза

________________________________________________________________________
(гариза бирүченең исеме)
___________________________________ максатларда ___________________күләмдә субсидия бирү мөмкинлеген карап тикшерүне сорый

Теркәлә:

1) шәхесне раслаучы документлар;

2) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

3) гариза бирү датасына кадәр ике ел дәвамында хуҗалык итүче субъект тарафыннан җитештерелгән һәм (яки) сатылган товар төрләренең исеме, товарлар күләме яисә товар төрләрен күрсәтеп, әгәр ике елдан да ким булмаган эшчәнлек алып барса;

4) эшчәнлекнең төп күрсәткечләре турында расланган мәгълүматлар;

5) товарлар җитештерү (сату), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү белән бәйле рәвештә алынмаган керемнәр һәм (яки) тотылган чыгымнар фактын раслаучы документлар;

6) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына кире кайтару буенча кичектерелгән бурычның булмавы (булуы) турында мәгълүматлар, хокукый акт нигезендә субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләр бирү планлаштырыла һәм хокукый акт нигезендә субсидия бирү планлаштырыла торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты алдында срогы чыккан башка

бурычлар (мондый таләпләр хокукый актта каралган очракта) турында мәгълүматлар;

7) Россия Федераиясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы Карарының 3 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән максатларга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетыннан акчалар алу (алмау) турында мәгълүмат;

8) гариза бирүченең чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булган чит ил юридик затларының катнашу өлеше Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Дәүләт һәм территорияләр исемлегенә кертелгән чит ил юридик затлары булып тормавы турында мәгълүматлар, салым салуның ташламалы салым режимын һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) уздырганда мәгълүмат ачу һәм бирүне күздә тотмый торган салым салуның ташламалы салым режимын һәм (яисә) мондый юридик затларга карата тулаем 50 проценттан артып китә торган дәүләтләр һәм территорияләр;

9) юридик зат өчен гамәлгә кую документлары.

Җитәкче
М.У. имза

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Эшләр башкару (товарлар җитештерү, хезмәт күрсәтү) белән бәйле чыгымнарны каплауга алынмаган керемнәрне кайтаруга һәм (яки) финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) субсидия бирү буенча
____ номерлы Шартнамә

Яр Чаллы шәһәре «__» ________ 201_

Алга таба «Вәкаләтле орган» дип аталучы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты, Башкарма комитет Җитәкчесе йөзендә___________, бер яктан, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итүче._____________, алга таба «Алучы» йөзендә _________, Устав нигезендә эш итүче, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучы яклар нигезендә __________ түбәндәгеләр турында әлеге Шартнамәне төзеделәр:

1. Шартнамәнең предметы

1.1. Әлеге Шартнамәнең предметы булып Вәкаләтле орган тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан Алучыга Шәһәр Советы карары белән расланган _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ еллар план чорына субсидияләр бирү тора.__________ товарларны җитештерү, хезмәтләр күрсәтү) белән бәйле чыгымнарны каплауга һәм (яки) финанс яктан тәэмин итүгә (кайтаруга)___________, ____________күләмдә.

1.2. Бирелә торган субсидия максатчан характерда була һәм әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында каралмаган максатларда кулланыла алмый.

1.3. Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан товарлар җитештерү (сату), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидияләр бирүне җайга сала торган хокукый акт:

1)____________________________________________________________;

2)____________________________________________________________.

Субсидияләр бирү шартлары һәм (яисә) максатлары нигезендә субсидияләр алучыларның алынган акчаларыннан файдалануын алга таба раслау таләбеннән башка товарлар җитештерү (сату), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарны каплау тәртибендә субсидияләр бирүне һәм (яисә) чыгымнарны каплау тәртибендә субсидияләр бирүне җайга сала торган хокукый акт:

1)____________________________________________________________;

2)____________________________________________________________

1.4. Иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүне кулланучылар категориясе (физик затлар)

1)____________________________________________________________;

2)____________________________________________________________.

1.5. Иҗтимагый файдалы хезмәтнең эчтәлеге һәм аны күрсәтү шартлары (формалары):

1)____________________________________________________________

2)____________________________________________________________ .

1.6. Иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү күләмен һәм сыйфатын яки күләмен характерлаучы күрсәткечләр______________________________________________________

1.7 Иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү күләмен характерлаучы билгеләнгән күрсәткечләрдән рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышлар______________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

1.8. Иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү тәртибен (стандартын) билгели торган норматив хокукый акт реквизитлары, ә мондый норматив хокукый акт булмаганда – бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче тарафыннан билгеләнә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүгә карата таләпләр______________________________________________________.

1.9. Иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдән файдаланучыларга мәгълүмат бирү ысуллары, формалары һәм сроклары__________________________________________________.

2. Якларның хокуклары

2.1. Вәкаләтле орган хокуклы:

2.1.1. әлеге Шартнамә буенча бирелә торган субсидия Алучының аны максатчан һәм нәтиҗәле файдалануын контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.1.2. Алучыдан алынган керемнәр һәм (яки) фактта башкарылган эшләр (товарлар җитештерү, хезмәтләр күрсәтү) белән бәйле чыгымнар турында хисап алырга____________, нигезләү документлары (счетлар, башкарылган эшләр актлары (җитештерелгән товарлар, күрсәтелгән хезмәтләр), башкарылган эшләрнең (җитештерелгән товарлар, күрсәтелгән хезмәтләр) бәясе турында мәгълүмат);

2.1.3. әлеге Шартнамәнең үтәлеше белән бәйле мәсьәләләр буенча Алучыдан өстәмә мәгълүмат сорарга һәм алырга;

2.1.4. субсидия бирүдән баш тартырга яисә бирелә торган субсидия күләмен билгеләнгән тәртиптә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм ____ елда әлеге максатларга каралган финанс чыгымнары күләмнәре кимегән очракта, шулай ук Алучыга әлеге Шартнамә буенча йөкләмәләрне тиешенчә үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән документларны тапшырган очракта, бирелә торган субсидия күләмен киметергә;

2.1.5. аны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, субсидияне кире кайтару турында карар кабул итәргә;

2.1.6. субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен билгеләргә.

2.2. Алучы, муниципаль хокукый актларда һәм әлеге Шартнамәдә билгеләнгән шартларны үтәгәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән субсидия алу хокукына ия.

2.3. Алучы Башкарма комитетның финанс идарәсе тарафыннан эчке муниципаль контроль үткәрүгә ризалыгын белдерә.

3. Якларның бурычлары

3.1. Алучы бурычлы:

3.1.1. субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәргә;

3.1.2. вәкаләтле органга __________ кадәр товар җитештерү, хезмәт күрсәтү белән бәйле алынмаган керемнәр һәм (яки) фактта тотылган чыгымнар турында хисап бирергә; нигезләү документлары (счетлар, башкарылган эшләр актлары (башкарылган товарлар, күрсәтелгән хезмәтләр), башкарылган эшләрнең (башкарылган товарлар, күрсәтелгән хезмәтләр) бәясе турында мәгълүмат);

3.1.3. әлеге Шартнамә буенча бирелә торган субсидияләрдән максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

3.1.4. башкарылган эшләрнең (товарлар җитештерү, күрсәтелгән хезмәтләрнең) сыйфатын тәэмин итәргә.

3.1.5. субсидия алучы тарафыннан әлеге шартнамәдә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, 10 эш көне эчендә шәһәр бюджеты кеременә субсидия суммасын кире кайтарырга.

3.1.6. 2 елдан да ким булмаган срокта иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкарган коммерцияле булмаган оешма белән килешүләр төзергә;

3.1.7. иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү максатларында хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы белән килешү төзергә, аның формасы һәм шартлары бюджет акчаларын алучы һәм субсидия алучы буларак баш бүлүче арасында төзелгән килешүдә билгеләнә (мондый шартнамә төзү кирәклеге турында баш эш бирүче буларак карар кабул иткән очракта);

3.1.8. әлеге шартнамәне берьяклы тәртиптә өзүне тыюны үтәргә;

3.1.9 иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү өчен субсидия алучыга кирәкле эшләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тыш, аңа субсидия бирелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү өчен субсидия алучы тарафыннан башка юридик затларны җәлеп итүгә тыюны үтәргә;

3.1.10 федераль бюджеттан чит ил валютасы акчалары исәбеннән субсидияләр алучылар - юридик затлар тарафыннан, югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (җибәргәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган, шулай ук әлеге акчаларны хокукый акт белән билгеләнгән башка операцияләрне бирү максатларына ирешүгә бәйле операцияләрдән тыш, субсидия алучылар тарафыннан сатып алуны тыюны үтәргә.

3.1.11. вәкаләтле органга __________________ кадәр субсидияләр бирелә торган чыгымнарның (алынмаган керемнәр) юнәлешләре турында мәгълүмат (товарлар җитештерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарны кире кайтару тәртибендә субсидия алучылар алган акчалардан файдалануны алга таба раслау таләбеннән башка)

3.2. Вәкаләтле орган бурычлы:

3.2.1. Алучыга субсидияне әлеге Шартнамәдә каралган тәртиптә һәм шартларда күчерергә.

3.2.2. баш бүлүче буларак бюджет акчаларын алучы буларак әлеге Шартнамәдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, алучыга тотылган чыгымнарны кайтарырга;

3.2.3. Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында субсидия алучыларга ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына (товарлар җитештерү (сату), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарны киләчәктә субсидия алучылар алган акчалардан файдалануны раслау таләбеннән башка каплау һәм алынган керемнәрне каплау тәртибендә субсидия бирү очрагында) субсидияләр күчерергә.

## 4. Субсидия бирү тәртибе һәм шартлары

4.1. Әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында билгеләнгән субсидиянең гомуми күләме түбәндәге тәртиптә________________________________________________________________ Шәһәр Советы карары нигезендә исәпләнә_________ № __.

4.2. Субсидия күчерүнең срогы (периодиклыгы):

Субсидия, әлеге Шартнамәдә каралган Алучының исәп-хисап счетына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык Департаментының территориаль бүлегенә акча бүлеп бирүгә карап, расланган документлар (башкарылган эшләр актлары, җитештерелгән товарлар, күрсәтелгән хезмәтләр), башкарылган эшләрнең (җитештерелгән товарлар, күрсәтелгән хезмәтләр) бәясе турында белешмә) нигезендә Вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге тәртиптә күчерелә: _______________.

4.3. Субсидияләр әлеге Шартнамә төзелгәннән көннән башлап ун эш көненнән дә соңга калмыйча (товарлар җитештерү (сату), эшләр башкару,

хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарны каплау тәртибендә субсидияләр алучылар алган акчалардан файдалануны алга таба раслау таләбеннән башка субсидия бирү очрагында) күчерелә.

Вәкаләтле орган тарафыннан фактта күчерелгән субсидия суммасы, әлеге Шартнамә нигезендә башкаручы тарафыннан бирелә торган хисап күрсәткечләреннән кире кагылганда, әлеге Шартнамәнең 4.2 пункты нигезендә күчерелергә тиешле суммага тәгаллек кертелергә тиеш.

4.4. Нәтиҗәлелек күрсәткечләре:________________________________

4.5. Хисаплылыкка таләпләр_____________________________________.

4.6. Субсидияләр бирү һәм аларны бозган өчен җаваплылык шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру турында таләпләр

## 5. Шартнамәнең гамәлдә булу вакыты

5.1. Әлеге Шартнамә ике Як та имзалаган вакыттан башлап үз көченә керә һәм_______кадәр гамәлдә була.

## 6. Якларның җаваплылыгы

6.1. Әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгәнчә, субсидия Алучы субсидияне максатчан файдаланмаган очракта, Алучы Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган бюджет акчаларыннан максатчан файдаланмаган өчен җаваплы.

## 7. Бәхәсләрне карау тәртибе

7.1. Әлеге Шартнамә Яклар килешүе буенча өзелергә мөмкин.

7.2. Әлеге Шартнамә буенча барлык аңлашылмаучылыклар һәм бәхәсләр Якларның сөйләшүләр юлы белән хәл ителә.

7.3. Бәхәсне сөйләшүләр юлы белән җайга салу мөмкин булмаган очракта, бәхәс Россия Федерациясе законнары нигезендә Арбитраж судта карап тикшерелергә тиеш.

## 8. Башка шартлар

8.1. ______________________ һәм Башкарма комитетның финанс идарәсе
(тармак органы исеме)
субсидияләр бирү шартлары, максатлары үтәлешен һәм тәртибен тикшерә.

Алучы финанс идарәсе тарафыннан эчке муниципаль финанс контролен үткәрүгә риза.

8.2. Әлеге Шартнамәгә кертелгән барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр, әгәр алар язма рәвештә рәсмиләштерелгән, вәкаләтле затлар тарафыннан

имзаланган һәм ике Якның да мөһерләре белән таныкланган булса, гамәлдә булып санала.

Әлеге шартнамәгә үзгәрешләр кертү өчен нигез булып тора:

1) бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүчегә субсидияләр бирү өчен элегрәк җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметү;

2) ___

3) ___

8.3. Әлеге Шартнамә тигез юридик көчкә ия дүрт нөсхәдә төзелә, ике нөсхәсе – Вәкаләтле органга, бер нөсхәсе – Алучыга, бер нөсхәсе Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Яр Чаллы шәһәре буенча территориаль бүлегенә тапшырыла.

8.4. Агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан товарлар җитештерү (сату), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү максатларында бирелгән субсидияләрнең калдыкларын кире кайтару хисап финанс елында кулланылмаган очракта ___ гамәлгә ашырыла һәм түбәндәге тәртиптә___.

Хисап финанс елында кулланылмаган субсидия калдыгы, чираттагы финанс елының 1 гыйнварына, хисап чорыннан соң килүче финанс елының 10 февраленә кадәр шәһәр бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Хисап елыннан соң килә торган финанс елының 1 февраленә кадәр Алучы тармак органына субсидиядән файдалану турында Шартнамәгә ___ нче кушымта нигезендә форма буенча хисап тапшыра.

Субсидияләрнең файдаланылмаган калдыгы түләттерелергә тиеш,

агымдагы финанс елында шул ук максатларга җибәрү ихтыяҗы булу турында ___

Башкарма комитет тарафыннан карар кабул ителмәде.

9. Якларның юридик адреслары һәм реквизитлары

Эшләр башкару (товарлар җитештерү, хезмәт күрсәтү) белән бәйле чыгымнарны каплауга алынмаган керемнәрне кайтаруга һәм (яки) финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) субсидия бирү буенча шартнамәгә нче кушымта

Субсидиядән файдалану турында хисап

| №т/б | Субсидиянең төре | План билгеләнешләре | Фактта финансланган (агымдагы финанс елы башыннан үсә барган нәтиҗә белән) | Агымдагы финанс елы башыннан үсә барган нәтиҗә белән фактта тотылган чыгымнар (касса чыгымнары) | Файдаланылмаган акчаларның калдыклары (хисап чоры азагына) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | Барлыгы: | | | | | |

Җитәкче ______________________ ______________________________

(имза) (имза расшифровкасы)

Башкаручы ______________________ ___________ ______________________

(вазыйфа) (имза) (имза расшифровкасы)

Телефон: ______________________

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

## Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлләренең эзлеклелек блок-схемасы




Документларга запрос кирәк
юк
әйе
Финанс идарәсе белгече запрослар җибәрә
Хакимият органына җибәрелгән запрослар
Финанс идарәсе белгече документларны комиссиягә җибәрә
Комиссия алынган документларны карап тикшерә
Комиссиягә җибәрелгән документлар
Финанс идарәсе белгече муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартуга Регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләрнең булуын тикшерә
Мәгълүматлар белән тәэмин итүче белгечләр запросларны эшкәртә һәм мәгълүматларны яки документларның (мәгълүматларның) булмавы турында белдерү кәгазе бирә
Документлар (мәгълүматлар) яки баш тарту турында белдерү
Баш тарту өчен нигезләр
Юк
Бар
Финанс идарәсе белгече субсидия бирү турында шартнамә проектын әзерли һәм аны килештерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрә
Килештерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты
Финанс идарәсе белгече субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын әзерли һәм аны килештерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрә
Килештерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрелгән субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты
Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерә һәм килештерелгән документларны финанс идарәсе белгечено җибәрә
Килештерелгән һәм финанс идарәсе белгеченә җибәрелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты
Финанс идарәсе белгече субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерү өчен Башкарма комитетның тармак органы җитәкчесе урынбасарына җибәрә
Башкарма комитетның тармак органы җитәкчесе урынбасарына килештерү өчен җибәрелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты
Башкарма комитетның тармак органы җитәкчесе урынбасары субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерә һәм финанс идарәсе белгеченә җибәрә
Килештерелгән, финанс идарәсе белгеченә җибәрелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты
Финанс идарәсе белгече тапшырылган документларны килештерү өчен Башкарма комитетның Хокук идарәсенә җибәрә
Башкарма комитетның Хокук идарәсенең кимчелекләр буенча


Юк
Бар
Башкарма комитетның Хокук идарәсе субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерә һәм финанс идарәсе белгеченә җибәрә
Килештерелгән һәм финанс идарәсе белгеченә җибәрелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты
Хокук идарәсе субсидия бирү турында шартнамә проектына яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектына кимчелекләр буенча күрсәтмәләр әзерли һәм кимчелекләрне төзәтү өчен финанс идарәсе белгеченә җибәрә
Финанс идарәсе белгеченә җибәрелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты
Финанс идарәсе белгече субсидия бирү турында шартнамә проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектына Башкарма комитетның Хокук идарәсе кимчелекләрен төзәтә һәм аларны Башкарма комитетның Хокук идарәсенә җибәрә
Финанс идарәсе белгече имзаланган субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә
Килештерелгән, имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты
Башкарма комитет Җитәкчесе субсидия бирү турында шартнамә проектын яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын имзалый һәм финанс идарәсе белгеченә җибәрә
Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм финанс идарәсе белгеченә җибәрелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты яки субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты
Финанс идарәсе белгече субсидия бирү турында шартнамә проектын имзалау өчен гариза бирүчене чакыра
Гариза бирүчегә имзалау өчен бирелгән субсидия бирү турында шартнамә проекты
Гариза бирүче субсидия бирү турында шартнамә проекты белән таныша, субсидия бирү турында шартнамә проектын дүрт нөсхәдә имзалый һәм теркәү өчен финанс идарәсе белгеченә кире кайтара
Субсидия бирү турында имзаланган, дүрт нөсхәдәге шартнамә проекты
Финанс идарәсе белгече субсидия бирү турында шартнамә проектын терки, субсидия бирү турында шартнамә проектының бер нөсхәсен гариза бирүчегә имза куйдырып бирә
Субсидия бирү турында гариза бирүчегә бирелгән шартнамә
Финанс идарәсе белгече муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту очрагында, субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын терки һәм гариза бирүчегә шәхсән бирә яисә почта аша җибәрә
Финанс идарәсе белгече тарафыннан теркәлгән һәм гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Башкарма комитетның финанс идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы | 305544 | nche.fbp@tatar.ru |
| Бюджет сәясәте бүлеге башлыгы | 305830 | Lyaysan.Galieva@tatar.ru |
| Финанс идарәсе белгече | 305679 | Gulnaz.Kiyamova@tatar.ru |

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
Кемнән:________________________

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
____________________________________________________________________________
(хезмәтнең исеме)

Язылган: ____________________________________________________________
____________________________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: __________________________________________________
____________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail: ______________________ адресына җибәрү юлы белән;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне:
____________________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче

орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | _________________ | ( _________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.и) |